ГЛАВА АБСАЛЯМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.2,
с.Абсалямово, 423957

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр урамы, 2 йорт,
Әбсәләм авылы, 423957

Тел.:(85593) 4-26-79, факс:4-26-79, e-mail: Absal.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«8» ноябрь 2024 ел № 5

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге составына керүче Әбсәләм торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26, 92 маддәләре нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы Нигезләмәгә таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 21 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы, Әбсәләм авылы, Совет урамы, 50Г йорт адресы буенча урнашкан Әбсәләм торак пунктының КФҮ бинасында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның якын туганнарыннан (әти-әниләре, ире (хатыны), балалары), Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләре, Россия армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар тыш, 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында Пушкин урамы буенча юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (вак ком-таш сатып алу, ташу, салу, эш өчен шартнамә буенча түләү);

- Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалар кору, (җирләү урыннарын төзекләндерү (Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында корыган агач, куакларны кисү; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитетына Әбсәләм торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В.Кубашева